СОВЕТ КАТМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Кирова, д.74, с. Катмыш,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422177

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАТМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Киров урамы, 74 нче йорт, Катмыш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы, 422177

тел.(факс): (85563) 2-72-03; e-mail: Katmish.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар

« 20 » сентябрь 2017 ел | № 2-25

## Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында" 23.03.2004 № 23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдумны үткәрергә:

««Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. Торак пункт чикләрендә су белән тәэмин итү, су чыгару оештыру:
   -Катмыш торак пунктында су белән тәэмин итү системасын капиталь ремонтлау;
   -Баскан һәм Ениикей Чишмә торак пунктларында су белән тәэмин итү системасын ремонтлау;

- су чыганагыннан (чишмәдән) су белән тәэмин итү линиясен үткәрү һәм Катмыш торак пунктын үзәк су белән тәэмин итү системасына кушу, су күтәрү манарасын сатып алу һәм урнаштыру.

2. Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру: - Баскан һәм Катмыш торак пунктларында Җиңү һәм ял паркын төзекләндерү.

«ӘЙЕ» «ЮК»

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Башлыгы И.Г.Габидуллинга йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /И.Г.Габидуллин /

СОВЕТ КАТМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА • НИЖНЕСУНЬСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ • РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИНН 1626001210